Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Иске Роман авыл җирлеге Советы

2021 елның 26 октябре №17/3

КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге Советының «Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2018 елның 23 июлендәге 51/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 июлендәге 51/2 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле бюджет проекты һәм җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап буенча гавами тыңлаулар муниципаль берәмлек башлыгы карары белән билгеләнә.»;

12 статьяның өченче абзацында «, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3.1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Иске Роман авыл җирлеге
башлыгы Р.Г. Дәүләтшина

Чистай шәһәре прокуроры вазыйфаларын башкаручы,
юстиция киңәшчесе
Ф.Ф. Әхмәтҗановка

Хокукый акт проектын
экспертизага җибәрү турында

Хөрмәтле Фидель Фәйзелхан улы!

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге Советының«Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 23 июлендәге 51\2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы проектка хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрүегезне сорыйм

Кушымта: проект 1 биттә, 1 нөсхәдә

Иске Роман авыл җирлеге
башлыгы Р.Г.Дәүләтшина

Чистай шәһәре прокуроры вазыйфаларын башкаручы,
юстиция киңәшчесе
Ф.Ф. Әхмәтҗановка

Хокукый акт проектын
экспертизага җибәрү турында

Хөрмәтле Фидель Фәйзелхан улы!

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Иске ромашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2021 елның 16 августындагы 14\1 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске ромашкино

авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Иске ромашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрне керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында»гы карар проектына хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрүегезне сорыйм

Кушымта: проект 2 биттә, 1 нөсхәдә

Иске Роман авыл җирлеге
башлыгы Р.Г.Дәүләтшина

Чистай шәһәре прокуроры вазыйфаларын башкаручы,
юстиция киңәшчесе
Ф.Ф. Әхмәтҗановка

Хокукый акт проектын
экспертизага җибәрү турында

Хөрмәтле Фидель Фәйзелхан улы!

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге Советының «Чистай муниципаль районы «Иске Роман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»2013 елның 31 июлендәге 6\2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карар проектына хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрүегезне сорыйм.

Кушымта: проект 1 биттә, 1 нөсхәдә

Иске Роман авыл җирлеге
башлыгы Р.Г.Дәүләтшина